**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нче йорт,
тел: 4-12-91

---

**2024лның 4 декабре** **79/3 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Усад авылы торак пунктында (Көнчыгыш, 2 нче Заовражная, Мәктәп, Черемуховая урамнары территориясе өлешендә) 2025 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлегендәге Усад торак пункты(Көнчыгыш, 2 нче Заовражная, Мәктәп, Черемуховая урамнары территориясе өлешендә) гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Усад торак пункты территориясендә(Көнчыгыш, 2 нче Заовражная, Мәктәп, Черемуховая урамнары территориясе өлешендә) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым салу акчаларын 10000 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү эшләре өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Столбище
авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы**:** И.Ю.Романова